**ГЛАВА**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2019 Күләгәш авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Байтуган авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1.Байтуган авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 9 октябренә 12 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауные расларга: «Күләгәш авыл җирлеге Байтуган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1.Янгын сүндерү машинасын карап тоту, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасы шоферына түләү.

2. Байтуган авылы урамнарын кардан чистарту.

3. Байтуган авылының үзәк өлешен төзекләндерү, агач кисү, куаклар кисү, койманы төзекләндерү).

«ӘЙЕ» «ЮК".

3. Күләгәш авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында.бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ю.Н.ВАСИЛЬЕВ